| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

13.12.2021 Казан ш. № 3811-р

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы, «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территорияләрендә газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зоналарын урнаштыру турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром газомоторное топливо» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУ хатын истә тотып (11.11.2021 № 1472/05), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан, газ бүлү челтәре объектының («Автомобильләргә газ тутыру компрессор станция-5нең саклау зонасы. Казан ш. Югары басымлы китерүче газүткәргеч») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 1757 +/- 20 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

2. Татарстан Республикасы «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан, газ бүлү челтәре объектының («Автомобильләргә газ тутыру компрессор станция-1нең саклау зонасы. Алабуга ш. Газүткәргеч») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм

график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 6361 +/- 17 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1 – 2 пунктларында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр**
**Ф.Ә.Әһлиуллин**